| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУНГЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br><br>Ул. Молодежная, д.68, д.Нижние Шаши, 422008<br>Тел.: (8-84369) 36-0-38; факс: 36-0-38 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КҮҢГӘР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br><br>Молодежная урамы., 68 нче йорт, Түбән Шашы авылы, 422008<br>Тел.: (8-84369) 36-0-38; факс: 36-0-38 |
|---|---|---|

**КАРАР**

“17” гыйнвар 2022 ел № 1

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 6 августында 18 нче номерлы карары белән кабул ителгән “Күңгәр авыл җирлеге территориясендә адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына” үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру» турындагыФедераль закон нигезендә, Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл башкарма комитеты карар бирә:

1. Күңгәр авыл башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 06 августындагы 18 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Күңгәр авыл җирлеге территориясендә адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 һәм 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта кулланыла торган төшенчәләр дәүләт адреслы реестрын алып бару һәм федераль мәгълүмати адреслы системаны эксплуатацияләүгә бәйлеРоссия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2013 нче елнын 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы «Федераль мәгълүмати адреслы система һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында"гы Федераль закон, 2014 чне елнын 19 ноябрендәге 1221 номерлы "Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару Кагыйдәләрен раслау турында"гы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә төгәл итеп кулланыла».

1.2. 1.5 пунктының 11-17 абзацларын 3-9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4-7 пунктчаларында«Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет " сүзләренә алмаштырырга»;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында«Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә Башкарма комитет яки муниципаль район җирле үзидарә органы " сүзләренә алмаштырырга»;

1.5. 2.6.4 пунктында«Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет»сүзләренә алмаштырырга».

2.Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Күңгәр авыл башкарма
комитеты җитәкчесе Сибгатуллин Д.Р.